**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№817**
**10.02.2023**

Башкарма комитетның 2020 елның 19 маендагы 2313 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 19 маендагы 2313 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Башкарма комитет һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан «Интернет» челтәрендә 8-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында каралган мәгълүматны урнаштыру;»;

2) 5 пунктта «Башкарма комитетның вазыйфаи затлары» сүзләреннән соң «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләрен өстәргә;

3) 9 пунктта «Җитәкчесенең» сүзен төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов